Amca gitmiş ve Eptiri'nin istediğinden fazlasını vermiş, hemen oracıkta yirmi beş lira çıkararak söz bohçasını alıp gelmiş" (4, 130).

### *1.3. Kız İstemeye Aracı Koyma*

Toplumda saygınlığı olan insanlar toplum içerisindeki hemen her önemli olayda ön sıralarda bulunur. Bu durum halk anlatılarında olduğu gibi modern anlatılar için de geçerlidir. Kız isteme gibi hassas bir konuda özellikle hatırı kırılamayacak kişilerin istemeye gönderilmesi olumlu neticeyi elde etmek açısından önemlidir. Tatarlarda bir kızı seven genç, kızın evine köyün en saygıdeğer, en açıkgözlü, atak ve ağzı söz yapan ağası veya ninesini gönderirmiş (8, 86). Bazen damat adayının anne-babası olmadığında ya da çok yaşlı olduğunda kız istemeye damadın başka yakınları da ön ayak olur.

Geçmişte de kız istemede aracılardan yardım alındığı belirtilir. Hunlarda, aracılar kız isteme için uygun zemini hazırlayan kimselerdir (1, 308). Anadolu'da, eskiden kız istemelerde aracı olarak toplumda önde gelenlerden yardım istense de günümüzde daha çok damat adayının yakınları (annesi, ninesi, yengesi vs.) bu işi yüklenmiş durumdadır.

Hikayede, Hafız'ın babası olup olmadığından bahsedilmez. Annesi ise çok yaşlıdır. Bu yüzden Hafız'a kız bakma işi yengesine kalmıştır.

"Bir yengem var. Her türlü yarım akıllılık, şaklabanlık, hafiflik onda. Güz gelip ekin harmana girdi mi o bana kız bakmaya başlıyor" ( 4, 120).

İmece esnasında bahsi geçen bir kız isteme durumu daha olmaktadır. Burada da yine aracılar bulunmaktadır. Şeyahmet, Eptireş Amcanın kızını istemeye Safa Amca isimli birini gönderir.

"Eptireş Amcanın Mahibeder'ini Şeyahmet istemiş. Safa Amca aracılığıyla haber gönderip vermeye niyetleri olduğunu öğrenmiş" (4, 130).

Başlık miktarında anlaşılamadığından kız verilmemiştir. Satkay isimli bir başkası bunu duyunca Hayrullah Amca isimli birini araya koyarak aynı kızı istetir.

"Satkay bunu birilerinde duyunca Hayrullah Amcayı istemeye gönderip, "Ne isterlerse ver; ne kadar verirsen ver, yalnız Mahibeder'i kaçırma demiş" (4, 130).

### *1.4. Düğün Zamanı*

Günümüzde, Anadolu'da düğün zamanları şehir ve kırsal kesimlerde farklılık göstermektedir. Şehir merkezlerinde modernleşmeyle beraber düğün salonlarının sunduğu imkanlardan dolayı düğünler yılın hemen her gününde yapılabilmektedir. Ancak aynı durum kırsal kesim için geçerli değildir. Kırsal kesimlerde düğünler çoğunlukla yaz aylarında, ekinler biçilip toplandığı, böylece maddi durumun daha iyi olduğu zamanlarda yapılmaktadır. Aynı şekilde Tatarlarda da düğün, nikah törenleri genelde sonbaharda, hasatlar toplanıp ambarlar dolduğu, yani tokluk zamanında yapılmıştır (7, 95).

Bibiesma, Hafız'a verilince önceden yapılan düğün hazırlıkları biter ve ekinler toplandıktan sonra düğün yapılır.

"Ekin, darı toplandıktan sonra bütün köyü toplayıp coşkulu bir düğün yaptık" (4, 137).

### Sonuç

A. İbrahimov'un toplumun aynası niteliğindeki ilk dönem eserleri Tatar toplumuna dair sosyal ve kültürel veriler taşımaktadır. Bu veriler esas alınarak yapılan çalışmada evlilik ile ilgili öğeler mukayese edilmiştir. Başlıklar altında verdiğimiz; 'evlenilecek kızın özellikleri', 'mehir ve başlık parası', 'kız istemeye aracı koyma' ve 'düğün zamanı' öğeleri Anadolu Türkleri ve Tatar toplumunun kültürlerinde ortaklık arz etmektedir. Bunların dışında çalışmanın sınırlı olmasından dolayı, ortak özellikler barındıran söz bohçası, evlenme yaşı, erkek seçme oyunu, mendil verme vs. gibi öğeler ele alınamamıştır. Ancak bu öğelerin de Anadolu'da pek çok yerde uygulandığı bilinmektedir. Kısacası, yapılan bu çalışmayla Türk ve Tatar toplumlarının tarihin kadim devirlerindeki ortak yaşam kaidelerinin halen devam ettiği anlaşılmaktadır.

### KAYNAKÇA


1. Alptekin A. B. Ceyhun'dan Ceyhan'a evlenme ile ilgili bazı kavramlar (kalın, saçı, okuntu, aşerme, toy) üzerine. – Erzurum: A. Ü. Türkiyat Araştırmaları Enstitüsü Dergisi, 2009. – S. 307–321.
2. Başçetinçelik A. Karaisalı ve çevresinde doğum, evlenme, ölüm. http://turkoloji.cu.edu.tr/CUKUROVA/makaleler/bascetin celik_karaisali.pdf. 2012. –S. 1–18.
3. Büyük Türkçe sözlük. 10. Baskı. –Ankara: TDK Yayınları, 2005. – 2243 s.
4. Vasiyet. (Çev: Kutlu F., Ersoy H., Arslan N.). – İzmir: Zambak Yayınları, 2005. –144 s.
5. Gökyay O. Ş. Dede Korkut hikâyeleri. – İstanbul: Kabalcı Yayınevi, 2006. – 361 s.
6. Devellioğlu F. Osmanlıca-Türkçe ansiklopedik Lügat. 22. Baskı. – Ankara: Aydın Kitabevi Yayınları, 2005. – 1195 s.
7. Zaripova Çetin Ç. Tatar Türklerinin düğün geleneği. – Ankara: Modern Türklük Araştırmaları Dergisi, 2005. – S. 93–119.
8. Zaripova Çetin Ç. Tatar Türklerinin gelenek ve görenekleri. – Ankara: Karadeniz Dergisi Yayınları, 2009. –160 s.
9. Yarullina R. Büyük tatar yazarı Alimcan İbrahimov. – Ankara: Türksoy, 2007. – S. 37–40.
10. Yıldız Ç. El-Ferec Ba'de'ş-Şidde'de motif incelemesi (ilk yirmi hikâye). – Adıyaman: Yayımlanmamış yüksek lisans tezi Adıyaman Üniversitesi, 2011. – 213 s.
11. Kaplan M. Türk edebiyatı üzerine araştırmalar I. – İstanbul: Dergah Yayınları, 1976. – 578 s.
12. Türkiye dışındaki Türk edebiyatları antolojisi 18 Tatar edebiyatı II. – Ankara: Kültür Bakanlığı Yayınları, 2001. – 480 s.


# Г. ИБРАҺИМОВНЫҢ «ТАБИГАТЬ БАЛАЛАРЫ» ХИКӘЯСЕНДӘ СЮЖЕТ СТРУКТУРАСЫ


*Г. Р. Гайнуллина (Казан)*



Татарский рассказ прошлого столетия целесообразно рассматривать с точки зрения строения событийного ряда. В статье на примере рассказа классика татарской литературы Г. Ибрагимова выделяется несколько взаимосвязанных особенностей эпического сюжета.


Билгеле булганча, хикәя – татар әдәбиятында үзгәрешләргә иң сизгер жанр (3, 9) буларак тамгалана. Хәзерге татар хикәясенең сюжет структурасындагы үзгәрешләрне бер гасыр элгәре иҗат ителгән эпик

текстның корылышын өйрәнү аша ачыкларга мөмкин.

Әдәбият белемендә эпик сюжет үстерелешен тәэмин итүче берничә үзенчәлекне аерып карау кабул ителгән (4, 233). Беренче – үзәк вакыйганы кабатлау – дупликация принцибы «эпик сюжетны оештыручы төп элемент» (4, 233) буларак билгеләнә. «Эпик сюжет нигезендә каршы якларның тотрыксыз тигезлеге ята, хәрәкәт исә – әлеге тигезлекнең вакытлыча җимерелеп, яңадан үз урынына кайтуы» (4, 233). Төп эпик ситуация кабатлана, кире симметрия (көзгеле композиция) закончалыгы саклана (4, 234).

Галимҗан Ибраһимовың «Табигать балалары» (1914) хикәясе 10 бүлектән тора. Хикәяләү егерме бер яшьлек Хафиз исеменнән алып барыла. Әсәрдә төп герой итеп алынган субъектив образның өйләнү тарихы бәян ителә. Беренче бүлектә өйләнергә нияте булган егетнең матди хәле яктыртыла: *«Өч атым, ике сыерым, ун баш сарыгым бар. Уткән көз өйне дә сипләтеп, алты почмаклы ясаттым. ... Насыйб булса, тагы бер-ике имән багана алып, киләсе көзгә капканы яңадан эшләтергә, кечерәк булса да, келәт салдырырга исәплим»* (1, 71). Урта хәлле, ялгыз егет *«кемгә башкода җибәрсә дә, сүзе кире кайтыр»,* дип шикләнми (1, 71). Тирә-якның ару тормышлы адәмнәреннән саналган Җамалый карт Фәхернисасы да, Шаһи карт кызы Бибиәсма да аңа кияүгә барырга әзер икәнлеген егет белә. Икенче бүлектә Бибиәсмага күңеле төшкән Хафиз *«сөеп алган, сөеп барган бәхетсез булалар имеш»* (1, 72) дип, өйләнергә кыймавының сәбәбен әйтә, беренче һәм төп проблема кыюсызлыкка кайтып кала.

Хикәянең өченче бүлегендә үткәнгә кайту (ретроспекция) алымы ярдәмендә Әсма белән Хафизның өч ел элек булган кара-каршы әйтешү вакыйгасы сөйләнә. Вакыйга өчен өмә ситуациясе сайлана, бишенче бүлектә кабатланган өмә «эшнең ахыры» да (1,74) булып тора. Шул рәвешле, егетнең кыюсызлыгын хәл итү өчен күмәк хезмәт вакыйгасы тасвирлана.

Эпик сюжет структурасының икенче закончалыгы булып ретардация тора. «Әкренәйтү (ретадация) алымы – хикәяләүне ашыкмыйча, аерым бер күренешләргә (пейзаж, портрет, фәлсәфи уйланулар, лирик чигенешләр, көчле хисләр) туктап алып бару дигән сүз» (2, 25). Өченче бүлектә Әсмага бәя бирелә: *«Әсма, диләр! Бибиәсма, диләр; карчыклар, иркәм, дип, аның аркасыннан кагалар; имеш, күргән җегетләр аның йөзенә, зифа буена, аяк атлавына хәйран булып сөйлиләр. Йөрәгемдә күптән ук аңар дәртем булса да, моңарчы бер сүз әйтү түгел, юньләп күрә дә алганым юк иде»* (1, 72). Иген уңган елны күрше Бәдри карчык оештырган өмәдә Әсма катнашачагын белүгә Хафиз *«минем эшем бик күп, үз ашлыгым да яланда, фәлән дип бер әйтүгә, азрак җилкәне кашырга уйлаган»* (1,72) җиреннән *«ярар, барымын»* дигәнен сизми дә кала (1, 72). Хезмәт белән үткән көнелле көн ахырында яшьләр бер-берсенә йөрәк түрендәге хисләрен әйтешеп таралышалар: *«Ни дияргә белмим инде, күңелемдә булганмы, үзем шуны эзләгәнмеме, әллә Ходай үзе туры китергәнме – ни дә булса бар, мин, урагымны атып бәреп, таллык эченә кергән генә идем, искәрмәстән, алдымда бер зифа буй күрдем: ул Әсма булып чыкты; тагын кызуладым, тагын омтылдым да, шул зифа буйны тотып ала язып, артыннан: "Әсма, Әсма, мин сине яратам!" – дип кычкырып җибәрдем. ... Шуңа каршы аның да үзенең көмеш тавышы белән: "Мин дә", – дигәнен ишетеп калдым. Миңа шуннан артыгы кирәкми дә иде»* (1,74).

Хафиз белән Бибиәсма турында тирә-якка сүзләр таралса да, тотыла язсалар да, кыюсыз егет проблемаларны уйлап табып кына тора. Дүртенче бүлектә *«тик әнкәйне ризалату гына авыр иде»* (1, 74), дип, алдагы проблема атала. Шул ук вакытта Хафиз, әнкәйнең картаюы бар, иптәшләрем инде күптән уллар-кызлар үстерә, дип, уңайсызланып йөри, *«агай-энеләрдән дә яхшы түгел, яшең егермеләрне үтеп, һаман өйләнмәгәч, алар минем өчен кызарып, гарьләнеп йөриләр бугай»* (1,74), дип тә уйлана. Шул рәвешле, сюжет хикәяләүченең уйланулары белән әкренәйтелә (ретардацияләнә).

Бишенче бүлектә өмә вакыйгасы кабатлана, дидек. Ураза тоткан вакытта Бибиәсманың атасы Шаһи бабай Ханбикә тугаендагы печәнлекне чабарга өмә итә (1, 74). Бирдә Шаһи бабай турындагы сүз сюжетны әкренәйтә: *«Ул – авылыбызның әйбәт картларыннан, аның Ибракаен солдатка алдылар, эш кулы ялгыз калды. Җитмәсә, тагы печән алдыннан гына менә дигән ике алашасын урлап киттеләр. ... Мондый кеше өмә итсә, бик ук ялгыз булмаганнар сүз кайтарырга килештермиләр инде, өстәвенә, аның Әсмасы да бар»* (1, 75).

Алтынчы бүлек – тулысы белән ретардация. Хикәяләүче уразада өмә оештыру авырлыгы, шул ук вакытта рәхәте турында уйлана: *«Рәхәт тә соң, валлаһи, шундый чакларда киң тугайларда күкрәк киереп печән чабулар!.»* (1, 75). Җиденче бүлектә пейзаж белән әкренәйтелгән өлештә печәнче егетләрнең ярдәм итәм, хезмәт күрсәтәм, дип ашкынып торулары бәяләнә: *«Көн утә аяз; күк әллә кая ерак иде; иртәнге салкында чабу җегетләргә бәйрәм генә булса да, соңгы чәй вакытлары утү белән кояш эсселәтә, кайберәүләрне йомшарта да башлады... Без һаман чабабыз... Шаһи картның үзенең дә эсседән күзләре агарган. Ул: "Я, балалар, без бит сәхәрдән ук килгән идек, әле дә күп чаптык... Инде кайтабыз дисәгез дә, сүзем юк", – диде»* (1, 75–76). Араларында Шәяхмәт дигәне эсседән егылгач кына, егетләр ял итеп алырга карар кылалар. Сигезенче бүлектә аяз яңгыр сурәте белән сюжет ретардацияләнә. Шул рәвешле, сюжетның кумулятив өлеше әкренәйтү вазифасын башкара.

Янәшә бирелгән ике пейзаж сюжетны үзгәртә – Хафиз күңелендәге рухи хәлсезлеккә китерә торган тотрыклы кыюсызлык *(«эсселек җиңә башлаган дигән сүз»)* кинәт кенә күптән көтелгән чишелеш *(«аяз яңгыр»)* белән алышына (1, 75, 78). Җыр образы герой күңелендәге хисләрнең иң югары ноктага җитүенә ишарәли.

Шулай итеп сюжет корылышында тугызынчы бүлек – *«бер якта – кояш, икенче якта – болыт»* (1, 78) – аяз яңгыр дип аталган табигать сурәтенең кабатланышы. Гыйлаҗи, Хафизны котыртып, Шаһи бабайдан Әсманы сорый. Шаһи карт та югалып калмый: *«Менә Кәрим карт белән ярышыгыз, ике әйләнгәнче аны кайсыгыз җир буе калдырса, Әсма шуныкы!»* – ди (1, 78).

Циклик каймалап алу, ягъни башлам һәм бетем өлешләренең кабатлану закончалыгы да үтәлә. Унынчы бүлектәге чишелеш – Хафизга кыюсызлыгын җиңәргә шарт тудыру, ягъни Кәрим картның күз күреме җирдә артта калуы, тиз арада Хафизның келәт белән капкасын

эшләтүе, иген-тару җыйгач, җәйне котмичә, кыш көне үк шаулатып туй итүе әйтелә. Егетнең *«сөеп алган, сөеп барган бәхетсез булалар имеш, эт көнендә гомерләре үтә»* (1, 72) дигән шиге акланмый: *«Без бик яхшы торабыз. Бөтен авылда безне мактап сөйлиләр. Инде озакламый балабыз да булачак»* (1, 80).

Күренгәнчә, Г. Ибраһимовның «Табигать балалары» хикәясендә төп эпик ситуация кабатлана, кире симметрия, циклик һәм кумулятив схемаларның тигезлеге дип аталган закончалыклар саклана. Бер гасыр үткәнгә нисбәтле классик хикәя сюжет структурасы җәһәтеннән гаҗәп дәрәҗәдә төгәл булуы белән игътибарны җәлеп итә.

ӘДӘБИЯТ


1. Ибраһимов Г. Табигать балалары // Татар хикәясе антологиясе. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2001. – Б. 71–80.

2. Әдәбият белеме: Терминнар һәм төшенчәләр сүзлеге. – Казан: Мәгариф, 2007. – 231 б.

3. Заһидуллина Д. Яңа дулкында (1980–2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык). – Казан: Мәгариф, 2006. – 255 б.

4. Теория литературы. Том III. Роды и жанры (основные проблемы в историческом освещении). – М.: ИМЛИ РАН, 2003. – 592 с.


# Г. ИБРАҺИМОВ ХИКӘЯЛӘРЕНДӘ БАЛА ОБРАЗЫ


***Ф. А. Гафурова (Уфа)***



В статье рассматривается вопрос воплощения образа детей в рассказах Г. Ибрагимова. Анализируются психологизм, драматизм в описании событий из жизни героев.


Һәр дәвернең алдынгы әдипләре баланың чынбарлыкны танып белүендә, аның эстетик зәвыгын, характерын формалаштыруда куәтле чара итеп әдәбиятны санаганнар. Татар әдәбияты классигы Галимҗан Ибраһимов татар балалар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертә. Г. Ибраһимовның һәр хикәясе татар балалар әдәбияты өчен яңалык була. Язучының «Яз башы», «Карт ялчы», «Көтүчеләр» исемле хикәяләре белән татар балалар әдәбиятына заманның иҗтимагый хәлләре килеп керде, хезмәт иясе баласы уңай герой дәрәҗәсенә күтәрелде, ярлы баласының эчке матурлыгы, бай рухи дөньясы ачылып китте, ул бәхетле булырга хокуклы һәм шуның өчен көрәшергә сәләтле итеп бирелде. Балаларга багышланган беренче хикәясе «Яз башы» 1910 елда дөнья күрә. Хикәядә сурәтләнгән вакыйгалар беренче заттан –Салих авызыннан сөйләтелә. Салих – урта хәлле крестьян малае. Авылның матур табигате, әти-әнисенең ягымлы мөнәсәбәте, гомумән яшьлек ваемсызлыгы аны назлап, иркәләп үстерә. Ләкин мондый ваемсыз тормыш озак дәвам итми. Бераз үсә төшкәч, аны күңеленә якын һәммә нәрсәдән – туган авылыннан, аның сихри табигатеннән, кадерле әти-әнисеннән, бергә уйнаган иптәш малайларыннан аерып, мәдрәсәгә илтәләр. Моңа кадәр әнисе кочагыннан бер җиргә дә чыкмаган сабый балага кыш буена читтә яшәү, тар мәдрәсә кысаларында бикләнеп яту җиңел түгел, билгеле. Ул бик сагына, язучы әлеге мизгелләрне, герой төннәрен йокларга яткач, юрган астында балавыз сыккан чаклар белән тулыландыра. Түземсезлек белән яз җитүен, мәдрәсәдән кайтыр вакытларын көткән Салих туган җирендә, яңадан табигать кочагында, кадерле әнисе янында, бергә үскән иптәшләре арасында гәүдәләндерелә.

Биредә язучы беренче хикәяләрендәге кебек, вакыйгаларны сөйләп чыгу юлыннан бармый. Ул әһәмиятле бер моментны – сабыйның озак вакытлар аерылып торганнан соң яңадан әнисе белән күрешү моментын сайлап ала да, шул вакытта ана белән балада булган рухи халәтне сурәтли, ана һәм бала тормышындагы төп сызыкларны бирүгә ирешә. Хикәядән ананың буй-сынын, аның йөреш-килбәтен һәм характерын гына түгел, хәтта тормышының үткәне белән киләчәген дә күз алдына китереп була (1, 13). Аның «арып, талган куллары» һәм «саргылт йөзе» дүрт стена эченә бикләнеп яшәүче, авыр физик хезмәттән җәфа чигүче татар хатынының типик язмышын сөйли. Ананың бөтен өмет һәм теләкләре шул сабыйга бәгланган булуы да аңлашыла. Автор характерлы калку моментларны сайлап ала һәм аларны җанлы образлар аша тасвирлап күрсәтә, типик картиналар тудыра. Әсәрдә һәммәсе табигый, һәммәсе тормышчан килеп чыккан: мәдрәсәдән кайтып төшкән сабый баланың әнисе янында утырып берәр чынаяк чәй эчкәч тә, тизрәк ишек алдына, иптәш малайлары янына атылуы да, аннан соң алар белән бергәләшеп табигать кочагына ташлануы да.

Кыш буена аерылып торган крестьян малаена барысы да кадерле: «түтәл вә агачлар белән тулган бакчасы да», мал-туар исе сеңгән абзар-куралары, яшел хәтфә белән капланган инеш буйлары да, балык тоткан тугайлары һәм төнлә ат сакларга йөргән урманнары да. Салихның хисләре шулкадәр мул булып ташый, эчке кичерешләре шул кадәр көчле һәм киеренке, хәтта сабый йөрәге күтәрә алмый. Аның хыял-фантазиясе табигать дөньясында булган үзгәрешләргә гаять сизгер. Ә табигать дөньясы аның күңеле белән уйнаган шикелле: ул, әйтерсең, үзенең нәфислеге һәм йомшаклыгы белән кытыклап көлдерә дә, гүзәллеге белән шатландыра һәм сөендерә дә, дәртлелеге белән күкләргә ашырырдай итеп җилкендерә дә. Ләкин табигать вакыты белән усал һәм рәхимсез, шомлы һәм куркыныч та. Аның дәһшәтле минутлары сабый хыялында хәвефле күренешләр тудыра, аны кайгыга сала, хәтта һушыннан яздыра.

Халык гасырлар дәвамында җеннәр, пәриләр, аждаһа, су анасы, убырлы карчык шикелле хыялый образлар иҗат иткән. Бу куркыныч әкиятләрне шәкертләр мәдрәсәләрдә тыңлаганнар, гаиләдә ата-аналар тәрбия чарасы итеп кулланганнар. «Яз башы» хикәясендә Г. Ибраһимов мондый әкиятләрнең, тәрбия чарасы булырак, зарарлы булуын, шәхесне куркак итеп үстерүен